ГЛАВА
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.04.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 01-125**

Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы турында

Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру максатында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (210 ст.), «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 октябрендәге 799 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы төзергә.
2. Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы турындагы нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы составын 2 нче кушымтада каралганча расларга.
4. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

- 2013 елның 08 августындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы турында» 02-38 номерлы;
- 2013 елның 29 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 02-59 номерлы;
- 2014 елның 21 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 02-136 номерлы;
- 2015 елның 10 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-209 номерлы;
- 2015 елның 29 октябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-240 номерлы;
- 2016 елның 29 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-43 номерлы;

- 2018 елның 03 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-184 номерлы;

- 2018 елның 26 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-291 номерлы;

- 2019 елның 13 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-261 номерлы;

- 2022 елның 17 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-03-94 номерлы;

-2022 елның 24 августындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» 01-323 номерлы.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Башлыгының
2024 елның 22 апрелендәге
01-125 номерлы карарына
1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча
Координация советы турындагы
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Зеленодольск муниципаль районының хезмәтне саклау буенча Координация советы (алга таба - Совет) Зеленодольск муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында төзелә.
1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының хезмәтне саклау өлкәсендәге закон чыгару һәм башка норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.
1.3. Совет киңәшү, методик һәм консультатив орган булып тора.
1.4. Совет үз эшчәнлеген җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләре, хезмәтне саклау, күзәтчелек һәм контроль өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары, социаль иминият фонды, профсоюзлар берләшмәләре һәм башка иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлегендә алып бара.
1.5. Совет рәисе булып Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары тора. Рәис булмаганда Совет эшчәнлегенә җитәкчелек итү аның урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.
1.6. Совет составы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана. Совет составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, төрле милек рәвешләрендәге оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының җирле органнары, профсоюзлар һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре (килешү буенча) керергә мөмкин.

2. Координация советы бурычлары.

- хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклауның территориаль программасын эшләү һәм раслау;
- төрле милек рәвешләрендәге оешмаларда хезмәт шартларының һәм саклауның торышын анализлау һәм аларны яхшырту чараларын эшләү;
- эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау таләпләрен үтәүләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыруга ярдәм итү;
- оешмаларның хезмәтне саклау хезмәтләренә методик һәм оештыру ярдәме күрсәтү;
- хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;
- оешма җитәкчеләре һәм белгечләре, хезмәтне саклау органнары вәкилләре, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче башкарма хакимият органнары, оешмалар һәм лабораторияләр вәкилләре, фәнни оешмалар, медицина учреждениеләре, хезмәтне саклау буенча уку үзәкләре, шулай ук хезмәтне саклау буенча башка чаралар катнашында семинарлар, киңәшмәләр, түгәрәк өстәлләр, хезмәтне саклау көннәре уздыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- барлык оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар арасында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча смотр-конкурслар үткәрүгә ярдәм итү.

## 3. Координация советы функцияләре.

- хезмәтне саклау буенча гамәлдәге законнарны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый;
- хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программа эшләү өчен эшче төркемнәр төзи;
- хезмәт шартларын яхшыртуның һәм хезмәтне саклауның территориаль программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тора;
- барлык оештыру-хокукый рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга смотрларда - хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту конкурсларында катнашуда булышлык күрсәтә;
- 50 кешедән артык эшләүче оешмаларда хезмәтне саклау хезмәтләрен булдыруга ярдәм итә;
- төркемдәге бәхетсезлек очракларының, үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен һәм эш бирүчеләрнең аларны бетерү буенча күрелгән чараларын карый;
- хезмәт шартлары буенча эш урыннарын аттестацияләүне активлаштыруга аннан соң барлык милек формасындагы оешмаларда хезмәтне саклау буенча эшләрне сертификацияләүгә ярдәм итә;
- эш бирүчеләрне производство травматизмын кисәтү, һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү, эш урыннарында хезмәт шартларын яхшырту һәм саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру турында тыңлый;
- оешмаларда хезмәтне саклау турында килешүләр төзү эшенең агымдагы торышын, хезмәтне саклау буенча җитәкчеләрне һәм белгечләрне укытуны, хезмәткәрләрне индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итүне карый;
- күзәтчелек һәм контроль органнарына хезмәтне саклау турындагы закон таләпләрен бозуга, югары дәрәҗәдәге җитештерү травматизмы һәм һөнәри авыруларга юл куйган эш бирүчеләргә карата чаралар күрү турында тәкъдимнәр кертә.

## 4. Совет эше регламенты.

4.1. Совет үз эшчәнлеген Совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә төзелгән эш планы буенча гамәлгә ашыра.
4.2. Совет эшенең төп формасы булып Советның еллык эш планына ярашлы рәвештә, әмма аена 1 тапкырдан да сирәгрәк үткәрелми торган утырышлар тора. Советның чираттагы утырышының датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында аның әгъзалары, утырыш уздырылырга тиеш булган көннән 7 көннән дә соңга калмыйча, хәбәр ителергә тиеш.
4.3. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.
4.4. Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашучы Совет әгъзаларының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.
4.5. Совет карарлары тәкъдим итү характерында.
4.6. Совет утырышлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга Совет рәисе һәм җаваплы секретарь кул куя. Беркетмәнең күчермәләре Совет әгъзаларына һәм тиешле оешмаларга җибәрелә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башлыгының
2024 елның 22 апрелендәге
01-125 номерлы карарына
2 нче кушымта
______________.

**Зеленодольск муниципаль районында**
**хезмәтне саклау буенча Координация советы**
**СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Кадникова Эльза Ренат кызы | ЗМР Башлыгы урынбасары, рәис |
| 2 | Бауэр Анастасия Сергеевна | ЗМР Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, рәис урынбасары (килешү буенча) |
| 3 | Донченко Эдуард Николаевич | Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бүлекчәсенең бурычы белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 4 | Әсәдуллина Динә Рамил кызы | ЗМР Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлегенең баш белгече, секретарь (килешү буенча) |
| Координация советы әгъзалары: | | |
| 5 | Мәхмүтов Ирик Абдрахман улы | «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| 6 | Минһаҗев Нияз Наил улы | «Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| 7 | Зиннуров Рамил Наил улы | «Зеленодольск муниципаль районының техник күзәтчелек хезмәте» МУП җитәкчесе (килешү буенча) |
| 8 | Гататдинова Светлана Владимировна | «Зеленодольск шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча) |
| 9 | Зәйнетдинова Алсу Хәмит кызы | Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторы урынбасары (хезмәтне саклау буенча) (килешү буенча) |
| 10 | Шәмсетдинов Рунар Рафикъ улы | Россия Тикшерү комитетының ТР буенча тикшерү идарәсенең Зеленодольск шәһәрендәге тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 11 | Анемподистова Евгения Викторовна | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ хезмәтне саклау белгече (килешү буенча) |
| 12 | Хөсәенова Гөлнара Талыйп кызы | Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Зеленодольск муниципаль районындагы территориаль бүлеге һәм Зеленодольск шәһәрендәге баш эксперты (килешү буенча) |
| 13 | Антипов Константин Сергеевич | «ПОЗиС» АҖ профсоюз комитеты рәисе (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | Шилова Ольга Николаевна | Зеленодольск муниципаль районы агросәнәгать комплексы предприятиеләренең профсоюз комитетлары рәисе (килешү буенча) |
| 15 | Яковлева Ольга Владимировна | «ПОЗиС» АЖ хезмәтне саклау бюросы башлыгы (килешү буенча) |
| 16 | Игнатьев Павел Николаевич | «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АЖ хезмәтне саклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 17 | Хәсәнова Резеда Госман кызы | «Зеленодольскгаз» ЭПУ баш инженер урынбасары - хезмәтне саклау бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 18 | Воронов Виктор Николаевич | «ТДК» ҖЧҖ хезмәтне саклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 19 | Хәбибуллина Әлфинә Фәрид кызы | «Полюс - Альфа» ПКФ» ҖЧҖ хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |